ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УСАД АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Усад авылы, Совет ур.,41

СОВЕТ УСАДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН422711,
Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Усады, ул. Советская, 41

Тел./факс: +7(84365) 73-2-75, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

КАРАР
22 октябрь 2019 ел

РЕШЕНИЕ
№ 192

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы һәм “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясын гамәлгә ашыру максатында, Усад авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны аны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Үз көчен югалткан дип танырга:

Усад авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында”, 2018 елның 24 сентябрендәге 147 номерлы карарын;

Усад авыл җирлеге Советының “Усад авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмә турында”, 2018 елның 24 сентябрендәге 147 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” 2019 елның 21 июнендәге 176 номерлы карары.

3. Әлеге карар аны рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Аның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
Җирлек башлыгы урынбасары Д.В.Нигметзянова

Кушымта
РАСЛАНГАН
ТР Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге
Советы карары белән
22 октябрь 2019 ел № 192

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны уздыру тәртибе турында НИГЕЗЛӘМӘ**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы һәм “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә эшләнгән.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданнар җыены гомуми, тигез һәм халыкның турыдан-туры01
1.2. ЭЮ ихтыярын белдерүе нигезендә үткәрелә.4.ңхЭ Y/.ү2
1.3.

1.2. Гражданнар җыенында торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган кешеләр катнашырга хокуклы.

1.3. Гражданнар җыенында катнашу ирекле һәм үз теләге белән тормышка ашырыла.

1.4. Гражданнар җыенда шәхсән үзләре катнашалар һәм аларның һәркайсы бер тавышка ия.

1.5. Гражданнар җыены турыдан-туры халыкның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүе максатында үткәрелә.

1.6 Әгәр дә торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган халкының яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә җыелу мөмкинлеге булмаса, гражданнар җыены Устав нигезендә этаплап уздырыла.

## Гражданнар җыенының вәкаләтләре

1.6. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

күрсәтелгән торак пункт керә торган, күрсәтелгән торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертелергә тиешле торак пунктта җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;

җирлекнең чикләрне үзгәртү, күрсәтелгән җирлекне үзгәртеп кору Усад авыл җирлеге Советы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла;

җирлекнең Усад авыл җирлеге Советы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан тормышка ашырыла торган җирлектә, әгәр сайлау хокукына ия җирлек кешеләренең саны 100 дән артык булса, җирлекнең вәкаләтле органын булдыру, аның саны һәм вәкаләтләр срогы турындагы мәсьәлә буенча;

җирлекнең Усад авыл җирлеге Советы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан тормышка ашырыла торган җирлектә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча;

җирлек составына керә торган яки муниципаль район чикләрендә авыллар арасындагы территориядә урнашкан торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча;

авыллар арасындагы территориядә урнашкан торак пунктта халыкның инициативасын күрсәтү максатында җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйләнгән мәсьәләләр буенча;

халык тыгыз урнашмаган яки барырга кыен булган урыннарда урнашкан җирлектә халык саны кимендә 100 кеше тәшкил итсә, җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча;

авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасы кандидатурасын күрсәтү, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен срогыннан элек туктату мәсьәләләре буенча;

авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфасына муниципаль хезмәт турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатында үткәрелергә мөмкин.

**Гражданнар җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү**

1.7. Җыенны уздыру Усад авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

1.8. Җыенга әзерләнү һәм аны үткәрү белән бәйләнгән чыгымнар муниципаль берәмлек бюджеты акчалары хисабына уздырыла.

## 2. Гражданнар җыенын чакыру тәртибе

Гражданнар җыенын үткәрү инициативасы

2.1. Торак пунктта гражданнар җыенын үткәрүдә инициативасы белән чыга:

- Усад авыл җирлеге Башлыгы;
- кимендә ун кешедән торган сайлау хокукына ия, гражданнар җыенында катнашырга хокукы булган (ягъни торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән, 18 яшькә җиткән эшкә сәләтле Россия Федерациясе гражданнары, шулай ук торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче һәм Россия Федерациясе халыкара шартнамәләре һәм федераль законнар нигезендә, җирле үзидарәне тормышка ашырганда катнашу хокукы булган чит ил гражданнары) кешеләр төркеме, шулай ук торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче һәм җирле үзидарәне тормышка ашырганда Россия Федерациясе һәм федераль законнарның халыкара килешүләре нигезендә хокукларга ия булучы чит ил гражданнары) торак пунктның халык төркеме.

2.2. Торак пункт кешеләренең инициативасы имзалар кәгазе (1 нче кушымта) яки инициатив төркем җыелышы беркетмәсе рәвешендә теркәлергә тиеш, анда түбәндәге мәсьәләләр күрсәтелеп, гражданнар җыены үткәрү инициативасын күрсәтү турында карар кабул ителә:

гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләр;

гражданнар җыенын үткәрү сроклары;

гражданнар җыенын чакыру турындагы инициативаны хуплаучы һәр гражданның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган көне, паспорты яки аны алмаштыручы

документының сериясе һәм номеры, яшәү урынындагы адресы, имзасы яки имза куелган дата.

2.3. Җыен үткәрү инициативасын яклап җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия булган, торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче, яшәү урынында теркәлгән гражданнар санының 5 процентын тәшкил итәргә, ләкин 10 имзадан да ким булырга тиеш түгел.

2.4. Имза кәгазьләре имзалар җыючe кешеләр тарафыннан тикшерелә, тикшерү датасы, фамилия, исем, әтисенең исеме, туган көне, паспорт яки аны алмаштыручы документ сериясе һәм номеры, яшәү урынындагы адресы күрсәтелә һәм муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.

## Гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе

2.5. Инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены Усад авыл җирлеге Советы карары белән (2 нче кушымта), ә муниципаль берәмлек башлыгы инициативасы буенча – Усад авыл җирлеге башлыгы карары белән (3 нче кушымта) кирәкле документлар килгән көннән соң 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Җирлек башлыгы яки муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы гражданнар җыенын, максатка ярашлы түгел, дип, үткәрүдән баш тартырга тиеш түгел.

2.7. Гражданнар җыенына кертелгән мәсьәлә Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килергә тиеш түгел. Гражданнар җыены мәсьәләсе кыска, ягъни аңа бертөрле, тәгаен җавап бирергә мөмкин булырлык итеп төзелергә тиеш.

2.8. Гражданнар җыенын билгеләү турындагы карарны рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе, аны күчерү Усад авыл җирлеге Уставы тарафыннан билгеләнә һәм муниципаль хокук актларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен муниципаль бермәлек уставында каралган тәртиптә бастырыла.

Гражданнар җыенын үткәрү турындагы муниципаль берәилек башлыгы яки Усад авыл җирлеге Советы карарларында гражданнар җыенына кертелә торган мәсьәлә, гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы – Усад авыл җирлеге Башкарма комитеты турында мәгълүмат күрсәтелә.

2.9. Гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү өчен җаваплы Усад авыл җирлеге Башкарма комитеты муниципаль берәмлек башлыгының яки Усад авыл җирлеге Советының гражданнар җыенын үткәрү турындагы карары нигезендә сайлау хокукына ия булган торак пункт кешеләренең исемлеген төзи, гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерли; муниципаль берәмлек массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән халыкка хәбәр итә (4 нче кушымта).

Усад авыл җирлеге Башкарма комитеты гражданнар җыенын үткәрү өчен бина бирергә тиеш.

2.9.1. Этаплап уздырыла торган гражданнар җыенын уздырганда торак пунктның халык санын аеру һәм гражданнар җыенын уздыру турында датаны билгеләү территориаль, вакыт сыйфатлары, шулай ук башка очракларда мөмкин.

2.9.2. Торак пункт халкының халык санын аеруны сайлау тәртибе гражданнар җыенын билгеләү турында муниципаль актта күрсәтелә (5,6 кушымталар).

2.9.3. Торак пункт кешеләренә гражданнар җыенын (этаплап гражданнар җыены) үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр ителә. Гражданнар җыенын (этаплап гражданнар җыены) билгеләү, гражданнар җыенын (этаплап гражданнар җыены) үткәрү вакыты һәм урыны турындагы карар гражданнар җыенын (этаплап гражданнар җыены) үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча мәҗбүри бастырып чыгарылырга тиеш. Этаплап гражданнар җыены уздыру вакыты һәм урыны гражданнар җыены ибилгеләү турында бер карар яки боерыкта күрсәтеләләр.

2.9.4. Гражданнар җыенын этаплап уздырган очракта, ул гражданнар җыенын уздыру турында карар кабул ителгән көннзн бер айдан артмаган срокта этаплап уздырыла. Гражданнар җыенын этаплап уздыруны күчергән вакытта, закон нигезендә җыен уздырылырга тиешле көннән соң айны исәпкә алып, 10 көннән дә соңга калмыйча гражданнар җыенын уздыруны күчерү турында карар каблу ителергә тиеш.

2.9.5. Җыенның һәр катнашучысы гражданнар җыенын үткәрү көненә кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсендә гражданнар җыены карарына кертелә торган, әлеге Нигезләмәнең 2.9 пунктында күрсәтелгән материаллар белән танышырга, шулай ук аларның күчермәсен алырга хокуклылар.

2.10. Гражданнар җыены турындагы Нигезләмә нигезендә гражданнар җыенын үткәрү датасы соңрак срокка күчерелергә мөмкин. Гражданнар җыенын күчерү турындагы карар җыенны үткәрү билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

## 3. Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе

3.1. Җыенга килгән гражданнар җыенда катнашучы кешеләрне теркәү өчен муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан билгеләнгән зат тарафыннан, җыенда катнашучы, торак пунктта яшәүчеләр исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукына ия кешеләр теркәлә. Әлеге исемлектә гражданның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган көне, яшәү урынынагы адресы, паспортының сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2. Җыенда катнашырга шулай ук хәлиткеч тавыш бирү хокукы булмаган, ләкин җыенда катнашырга теләк белдергән башка гражданнарга, предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләренә (әгәр җыенда ткишерелә торган мәсьәләләрне хәл итү алар эшчәнлеге белән бәйләнгән булса), башка массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә дә рөхсәт ителә.

3.3. Сайлау хокукына ия булучы торак пункт халкы исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта торак пункт кешесе Усад авыл җирлеге башлыгы рөхсәте белән теркәлә һәм җыенда катнашырга кертелә.

3.4. Гражданин шәхесен раслаучы (Россия Федерациясе гражданины паспорты, хәрби билеты, чит ил гражданинының паспорты, Россия Федерациясендә яшәүгә рөхсәт, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт һ.б.) документ язмаларның төгәлсезлеген (яки аларның булмавы) раслау булып хезмәт итә.

3.5. Гражданнар җыены анда сайлау хокукына ия булган торак пункт кешеләренең яртысыннан артыгы катнашканда тулы хокуклы була. Кворум булмаганда гражданнар җыенын үткәрүнең яңа датасын муниципаль берәмлек башлыгы билгели. Бу очракта гражданнар җыены гражданнар җыены үткәрү билгеләнгән көннән соң ун көннән дә иртәрәк үткәрелергә тиеш түгел.

3.6. Гражданнар җыены этаплап уздырылган очракта, төрле этапларда гражданнарның теләсә нинди санда килүе очрагында хокулы, ахырдан уздырылган барлык этапларның нәтиҗәләре буенча тавышларны саныйлар, шулай итеп җыен бербөтен кала.

3.7. Гражданнар җыенында тавыш бирү ачык яки яшерен була ала.

Тавыш бирү формасы турындагы карар гражданнар җыенында кабул ителә.

3.8. Яшерен тавыш биргәндә гражданнар җыенында катнашу өчен теркәлгән гражданинга тавыш бирү өчен бюллетень бирелә ( 7 нче кушымта).

3.9. Гражданнар җыенында муниципаль берәмлек башлыгы яки гражданнар җыенында теркәлгән катнашучылар арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш алган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын гражданнар җыенында катнашучылар тәкъдим итә ала.

3.10. Гражданнар җыены сәркатибне һәм хисап комиссиясен сайлый. Хисап комиссиясе әгъзалары саны өч кешедән ким була алмый.

Хисап комиссиясенә рәислек итүче керә алмый.

Хисап комиссиясе:

1) гражданнар җыенына килүче торак пункт халкын теркәүнең дөреслеген тикшерә, аларның гражданнар җыены эшендә катнашуга хокукы булган очракта;

2) гражданнар җыенының кворумын билгели (гражданнар җыеннарын этаплап уздырудан кала);

3) тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә;

4) тавышларны саный һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен билгели (гражданнар җыеннарын этаплап уздырудан кала);

5) тавыш бирү нәтиҗәләре буенча беркетмәләр төзи (гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча);

6) рәислек итүчегә тавыш бирү нәтиҗәләре буенча материалларны тапшыра (беркетмә, җыенда катнашучы гражданнар-катнашучылар исемлеге).

3.11. Гражданнар җыенының эш көненә өстәмә сорауларны рәислек итүче, муниципаль берәмлек башлыгы, гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар тарафыннан кертелә ала. Эш көненә мәҗбүри тәртиптә гражданнар җыенын чакыру инициаторлары керткән сораулар кертелә. Күрсәтелгән сораулар беренче чиратта карала. Гражданнар җыенының эш көненә кертү турындагы карар аның өчен җыенда катнашкан гражданнарның кимендә яртысы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

3.12. Этаплап гражданнар җыены уздырган вакытта шулай ук муниципаль берәмлек башлыгы яки  гражданнар җыенында теркәлгән катнашучылар арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш алган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын гражданнар җыенында катнашучылар тәкъдим итә ала.

3.13. Этаплап гражданнар җыенында тавыш бирү  ачык яки яшерен була ала.

Тавыш бирү формасы турындагы карар гражданнар җыенында кабул ителә.

3.14. Этаплап гражданнар җыенын уздырганда этаплап гражданнар җыенын уздыруның һәрбер этабында  хисап комиссиясе санынннан гражданнарның ачык тавыш бирү нәтиҗләре буенча, хисап комиссиясеннән берәр әгъза сайлана, алар кворумнарны һәм тавыш бирүнең нәтиҗәләрен санаганда комиссия составында эшлиләр (исәкрмә: җыенны ике этапта уздыру).

3.14.1 Торак пунктта гражданнар җыенын ике этапта уздырган вакытта хисап комиссиясе кворумнарны һәм тавыш бирүнең нәтиҗәләрен санаганда хисап комиссиясенең тулы составы белән эшлиләр.

3.15. Гражданнар җыены җыенда рәислек итүче тарафыннан ачыла. Җыенда рәислек итүче гражданнарның җыенын оештыра, тәртипне саклый, хисап комиссиясенең эшенә кураторлык итә, тикшерелә торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, тавыш бирүнең билгеләнгән тәртибен тәэмин итә.

3.16. Гражданнар җыенында сәркатиб беркетмә алып бара, анда гражданнар җыенын үткәрү көне һәм урыны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, карала торган сораулар буенча тавыш биргән гражданнар саны күрсәтелә (8 нче кушымта).

3.17. Этаплап гражданнар җыенын уздырганда, һәрбер гражданнар җыены этабында беркетмәләр алып барыла (9,10 нчы кушмталар), алар киләчәк бербөтен этаплап гражданнар җыенын уздыру беркетмәсенә берләштереләләр (11 нче кушымта), шула йук Хисап комиссиясе беркетмәләре (12, 13 нче кушымталар)  этаплап гражданнар җыенын уздыруда тавыш бирүләр  нәтиҗәләре буенча бербөтен Хисап комиссиясе беркетмәсенә берләштереләләр (14 нче кушымта).

3.18. Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе этаплап гражданнар җыены уздыру датасы, урыны һәм вакыты, көн тәртибе,  этаплы гражданнар  җыенында катнашкан гражданнарның гомуми саны, гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча тавыш бирүнең соңгы нәтиҗәләре турында мәгълүматларны үз эченә алалар. Йомгаклау

беркетмәсе җирлек башлыгы тарафынна имза куелган, аны киләчәктә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен гражданнар җыены турында карарга нигез булып тора.

3.19. Беркетмә җыенда рәислек итүче зат һәм җыен сәркатибе тарафыннан имзаланып, муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла. Җыенда катнашучылар исемлеге беркетмәгә теркәлә.

3.20. Этаплап гражданнар җыены уздыру нәтиҗәләре буенча Хисап комиссиясенең йомгаклау беркетмәсе этаплап гражданнар җыены уздыру датасы, урыны һәм вакыты, көн тәртибе, этаплап уздырылган җыеннар саны, этаплап гражданнар җыены буенча Хисап комиссиясе беркетмәләре саны, җыен уздыру өчен билгеләнгән һәм аның эшендә катнашырга хокукы булган территориядә яшәүче гражданнарның гомуми саны, җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны, ӘЙЕ, ЮК дип бирелгән тавышларның гомуми саны.

3.21. Беркетмә Хисап комиссиясе рәисе һәм Хисап комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзаланып, муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла.

## 4. Гражданнар җыенының карарлары

4.1. Гражданнар җыенында катнашучыларның сайлау хокукына ия булган яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, җыен карары кабул ителгән дип санала.

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокук актлары булып торалар, җирлек башлыгы тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлар регистрына кертелергә тиешләр (7, 8 нче кушымталар).

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары гражданнар җыенында җирлек Уставы билгеләгән, алар арасындагы вәкаләтләрне чикләү нигезендә кабул ителгән карарларны үтәүне тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар юкка чыгарылырга яки җыенда башка карар кабул итү юлы белән үзгәртелергә, яисә суд тәртибендә гамәлдән чыккан дип танылырга мөмкин.

4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм муниципаль хокукый актлар өчен таләпләр нигезендә рәсмиләштерелергә тиешләр.

4.6. Торак пункт кешеләренең турыдан-туры ихтыярын белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль хокук актын кабул итү (бастыру) таләп ителсә, компетенциясенә күрсәтелгән актны кабул итү (бастыру) керә торган җирле үзидарә органы яки вазыйфаи зат гражданнар җыенында кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән алып 15 көн эчендә тиешле мунициаль хокук актын әзерләү һәм (яки) кабул срогын билгеләргә тиешләр. Күрсәтелгән срок өч айдан арта алмый.

## Гражданнар җыенының карарларын үтәү

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри төстә үтәлергә тиешләр һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органнарының, аларның вазыйфаи затларының яки җирле үзидарә органнарының раславына мохтаҗ түгелләр.

4.8. Җыенда кабул ителгән карарларны үтәмәү закон нигезендә җаваплылыкка тартуга сәбәп булып тора.

1 нче кушымта

Татарстан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

ИМЗАЛАР КӘГАЗЕ

Без, түбәндә кул куючылар, ________________________________________________________
(гражданнар җыенын үткәрү сроклары)
гражданнар җыенын үткәрү инициативасын хуплыйбыз.
Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлегендә, түбәндәге тәгъбирле мәсьәлә
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________.

| № № т/б | Фамилия, исем, әтисенең исеме | Туу көне | Яшәү урыны адресы | Паспорт яки аны алмаштыручы документ сериясе, номеры | Имза кую датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Имзалар кәгазен раслыйм__________________________________________________
(имза җыючы кешенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме,
_____________________________________________________________________________
туу көне,паспорты яки аны алмаштыручы документының сериясе, номеры)

______________________ (имза һәм дата)

2 нче кушымта

Татарстан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УСАД АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422710, Татарстан Республикасы,
Биектау районы,
Усад авылы, Совет ур.,41

**СОВЕТ УСАДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан,
Высокогорский район,
с. Усады, ул. Советская, 41

Тел./факс: +7(84365) 73-2-75, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**«__» _______ 2019 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ ___**

**Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге ______________________ торак пунктында гражданнарның үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы һәм “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге ________________________торак пунктында 20** елның 00 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 20____ елда гражданнарга муниципаль районның (муниципаль берәмлек “шәһәр_________”) ________________ җирлеге _________________ торак пункты территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә (үзара салымнан азат ителгән гражданнардан кала) ___________ сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы?:

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән халыкка кабул иткәннән соң _______ көн эчендә җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Совет рәисе урынбасары,
Җирлек башлыгы урынбасары Д.В.Нигметзянова

3 нче кушымта

Татарстан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСАД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Усад авылы, Совет ур.,41

**ГЛАВА УСАДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422710, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Усады, ул. Советская, 41

Тел./факс: +7(84365) 73-2753, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНЕИЕ**

**«__» _______ 2019 ел** **№ ___**

**Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге _____________________ торак пунктында гражданнарның үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы һәм “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

**КАРАР ИТТЕ:**

Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге ________________________торак пунктында 20___ елның ______ _______ үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1. Гражданнар җыенына кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 20____ елда гражданнарга Биектау муниципаль районның Усад авыл җирлеге ________________ торак пункты территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә _________________ кала, һәм ______ сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы?:

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән халыкка кабул иткәннән соң ______ көн эчендә җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Совет рәисе урынбасары,
Җирлек башлыгы урынбасары Д.В.Нигметзянова

4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

_______________________________________

(муниципаль район исеме) (авыл җирлеге исеме)

_______________________________ сайлау хокукына ия кешеләр

(торак пункт исеме)

**ИСЕМЛЕГЕ**

«___» _________________ 20___ ел

